КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 июль г.Казань № 627

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятенә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) әлеге юридик зат милкендәге капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга (алга таба «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятенең устав капиталын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттырып) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 нче пункт, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге юридик затлар милкендәге капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга (алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттырып) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2019 елда акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятенә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы»

индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) акционерлар җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру өчен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Субсидия бирүгә күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы тора.

3. Субсидия «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларны һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру һәм үстерү» ярдәмче программасындагы «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү» чарасын тормышка ашыруга бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына:

бу карар үз көченә кергән көннән 10 көн эчендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятенә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) әлеге юридик зат милкендәге капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга (алга таба «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятенең устав капиталын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттырып) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү төзергә;

акционерлар җәмгыятенең устав капиталын Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле арттыруга юнәлдерелгән акционерлар җәмгыяте гамәлләрен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 июль, 627 нче
карарына 1 нче кушымта

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыяте милкендә булган, капиталь кертемнәр гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектлары

| Т/с | Капиталь төзелеш объекты исеме | Объектның куәтлеге | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы (ОКЕИ) буенча куәтлекне үлчәү берәмлеге | Инвестицияләү юнәлеше | Заказчының исеме | Төзүченең исеме | Файдалануга тапшыру вакыты | Объектның смета кыйммәте, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | | Капиталь кертемнәр күләме, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | барлыгы | шул исәптән өстәлгән кыйммәткә салым | шул исәптән проект документларын әзерләүгә, инженерлык эзләнүләрен үткәрүгә бүлеп бирелә торган акча күләме | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | барлыгы | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 4 нче корпус» | 76170,4 | кв. метр | төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 елның гыйнвары | 3 913 752,04 | 597 013,02 | 36 864,41 | 2 191 073,56 | 1 722 678,48 | – | 3 214 000,0 | 1 491 321,52 | 1 722 678,48 | – |
| 2. | «Синергия» автокомпонентлар җитештерү буенча индустриаль-технологик паркы. 3 нче корпус. ПАН-прекурсор җитештерү буенча заманча завод» | 5 000 | 1 елга тонна | төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 елның марты | 2 573 900,09 | 392 628,83 | 103 510,86 | 581 494,61 | 1 500 000,0 | 492 405,48 | 2 312 000,0 | 319 594,52 | 1 500 000,0 | 492 405,48 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 июль, 627 нче
карарына 2 нче кушымта

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы»
акционерлар җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасы бүлү

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) |
|---|---|---|
| 1. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 4 нче корпус» | 1 136 000,0 |
| 2. | «Синергия» автокомпонентлар җитештерү буенча индустриаль-технологик паркы.<br>3 нче корпус. ПАН-прекурсор җитештерү буенча заманча завод» | 332 000,0 |
| | Барлыгы | 1 468 000,0 |